КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 декабрь г.Казань № 1512

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карары белән расланган Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел,

20 гыйнвар, 25 нче; 2017 ел, 21 март, 167 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1113 нче, 2019 ел, 20 сентябрь, 861 нче, 2020 ел, 14 август, 684 нче, 2021 ел, 31 май, 399 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

5 пунктта:

беренче абзацта «Тәкъдимнәрне (заявкаларны) кабул итү бердәм порталда һәм рәсми сайтта сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырган көннең икенче көненнән соң календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла.» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү сроклары, сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен кабул итә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасы (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган биш календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«сайлап алуда катнашучы экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска тиеш.»;

13 пунктта:

өченче абзацта «, аның максатчан билгеләнеше» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

сигезенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

18 пунктта «нәтиҗәләре» сүзен «нәтиҗәнең мәгънәсе» сүзләренә алмаштырырга;

21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Министрлык субсидия алучы тарафыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә)

тикшерә. Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау, Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.»;

22 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы унбишенче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карары белән расланган Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 7 пунктының өченче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин